Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2:256)

# Ислам Нуры

№ 1 (629) 13 гыйнвар, 2017 ел (1438, Рабигүл-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Балалар өчен кышкы лагерьлар



Кышкы каникул чорында Чаллының “Рамазан”, “Ихлас” мәчетләре, мөхтәсибәтнең “Хәзинә” якшәмбе мәктәбе каршында балалар өчен көндезге лагерьлар эшләде. “Рамазан мәчетендә ул ике атна буена барды. 6 яшьтән 11 яшькә кадәрге 12 бала биредә гарәп алфавитын, иман нигезләрен өйрәнделәр, төрле спорт чараларына, сәяхәтләргә тартылдылар, тәмле ашлар белән сыйландылар. Таудан шуу, бау паркында бауларда йөрү, 2 нче татар гимназиясе спорт залында спорт уеннарында катнашу бик күңелле узды. Лагерьның соңгы көнендә - 6 гыйнварда балаларга истәлекле бүләкләр тапшырылды.

“Ихлас” мәчетендә балаларның кышкы ялы мәктәпкәчә яшьтәге кыз балаларның “Кар бөртеге” лагерыннан башланды. Ул 20-30 декабрь чорында эшләде. Бу лагерьга йөрүче нәниләр һәр көнне файдалы уздырдылар, өч мәртәбә туклану белән тәэмин ителделәр. Аларның һәр көне иртәнге зарядкадан башланды, күңелле уеннар белән тәмамланды. Балалар белән тәрбия темаларына әңгәмәләр уздырылды, торт бизәү, браслет, комлы пластилиннан фигуралар ясау буенча мастер-класслар күрсәтелде. Балаларның үзләре ясаган эшләре исә “Аллаһның нигъмәте: кышкы могҗиза” күргәзмәсендә урын алды. Балалар шулай ук “Торговый квартал” маркетының уеннар бүлмәсенә сәяхәт ясадылар.

Кызлардан соң “Ихлас” мәчете каршында өлкәнрәк малайлар өчен көндезге атналык лагерь эшләде. Аңа 8 малай йөрде. Программа бик бай булды: дәресләр, уеннар, викториналар, төрле бәйгеләр. Балалар ялдан бик тә канәгать калдылар.

Ә “Хәзинә” мәктәбендәге кызлар лагерында 18 бала ял итте.

**Рәсемнәрдә:** “Ихлас” мәчетендә ял итүче малайлар төшке аш вакытында; “Рамазан” мәчете лагерында ял итүчеләрнең тормышыннан күренешләр.







## Шифаханәдә гыйбадәт бүлмәләре булачак



Чаллының 5 нче шифахасендә (1/09, элеккеге КамАЗ шифаханәсе) мөселманнар һәм христианнар өчен гыйбадәт бүлмәләре ачарга әзерләнәләр. 9 гыйнварда шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин һәм аның урынбасары Фоат хәзрәт Мөхәммәтов шифаханәдә булып бу эшнең барышы белән таныштылар. Шифаханәнең баш табибы Зөфәр Мисбах улы Насрединов бу уңайдан болай диде: “Шифаханәбез шәһәр һәм якын-тирә районнары кешеләренә хезмәт күрсәтә. Бездә даими рәвештә 600дән артык кеше 13 юнәлеш буенча дәвалану ала. Әлбәттә, авыруларның рухи ихтыяҗларын да канәгатьләндерү бик мөһим. Чөнки рухы нык кеше тән авыруларын җиңелрәк кичерә, авыруны тизрәк җиңә. Гыйбадәт бүлмәсенә дин тотучы үз хезмәткәрләребез дә йөрер дип уйлыйм. Табиблар арасында да намаз укучылар бар.”

Булачак намаз бүлмәсе белән танышкач, хәзрәтләр башкарылган эшләрдән бик канәгать калдылар. Намаз бүлмәсе 1нче неврология бүлекчәсенең икенче катында җиһазлана. Аның идәненә келәм җәелгән, стенага намаз укырга өйрәткән плакатлар эленгән, дини әдәбият булдырылган. Янәшәдә генә комган куелган тәһарәтханә. Ә христианнар өчен гыйбадәт бүлмәсе 2 нче неврология бүлегендә әзерләнә.

Әлфәс хәзрәт баш табибка, аның ярдәмчеләренә ошбу юнәлештә башкарган хезмәтләре өчен рәхмәтен белдерде. “Авыруларга палатада намаз уку кыенрак. Чөнки кемгәдер уңайсызлык тудырырмын дип читенсенәсең, намазның бар шартларын үтәп булмый. Ә аерым бүлмәдә булу җанга тынычлык бирә. Коръән уку мөмкинчелеге дә булачак. Ягъни гыйбадәт бүлмәсе авыруларга өстәмә бер таяныч,”- диде ул. Әлфәс хәзрәтнең фикерен Фоат хәзрәт тә хуплады. Ул әлегрәк күп тапкырлар ошбу шифаханәдә дәваланган икән. Фоат хәзрәт шифаханә җитәкчелегенең клиентлар ихтыяҗына һәрвакыт игътибарлы булганлыкларын әйтә һәм 5 нче шифаханә башлангычына шәһәрнең башка шифаханәләре дә иярер дигән ышанычын белдерә.

**Рәсемдә:** мөселманнар өчен булачак гыйбадәт бүлмәсе белән танышу.

# Хәмер – шайтанның капканы

Бөек Раббыбыз Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә «Мәидә» сүрәсенең 90 нчы аятендә әйтә:«Ий мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннары һәртөрлесе дә, сынымнарга гыйбадәт итү — Аллаһудан башка мәхлукларга табыну эшләре, шулай ук ырымлану — багучылык эшләре хәрамдыр, шайтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер, һәлак булудан котылмаклыгыгыз өчен бу нәҗес эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять, котылырсыз — өстенлек табарсыз» ( 5:90).

Бу аятьтә бөтен галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгалә безгә, адәм балаларына, мәрхәмәт итә. Безне шушы хәмердән, отыш уеннарыннан һәм башка пычрак гамәлләрдән килгән бәла-казалардан, авырулардан һәм күңелсез хәлләрдән коткару өчен вәгазьли. Аллаһы Тәгалә безнең барыбызның да саусәламәт һәм бәхетле булуыбыз өчен дөньяда барысын да бар кылган. Җиде кат күк һәм җиде кат җир, таулар, далалар, урманнар, диңгезләр һәм барлык җәнлекләр дә адәм баласы өчен яратылган. Кайбер кешеләр кайвакыт сорау бирәләр: «Ә ни өчен соң алайса Аллаһы Тәгалә ул тыелган нәрсәләрне бар кылган һәм хәмернең дә булу- ына юл куйган? Аллаһ теләмәсә, хәмер булмас иде бит». Чыннан да, әгәр Раббыбыз теләмәсә, хәмернең җирдә әсәре дә булмас иде. Әмма шул ук вакытта без Раббыбызның күпме нигъмәтләреннән мәхрүм калыр идек.

Бүгенге көндә без нинди гаҗәеп фән үсеше чорында яшибез. Өйләребез утынсыз җылына, су кергән һәм чыккан, җирдә йөри торган, һавада оча торган, суда йөзә торган транспортларыбыз бар. Элекке заманда бабаларыбыз айлар буе йөргән юлларны без бер-ике сәгать өчендә йөреп чыга алабыз. Шифаханәләрдә нинди генә авыруларны дәваламыйлар, төрле операцияләр ясыйлар. Ә бит бу эшләрнең күбесендә төрле составтагы спирт кулланыла.

Бу дөньяда һәрбер нәрсәнең үз урыны бар, һәр бөҗәкнең дә үз кирәге бар. Бер генә төр бөҗәк югалса да аның артыннан бүтән төр кошлар һәм бөҗәкләр һәлак була башлый. Шуңа да хәмернең (спиртның) файдасын без бүгенге көндә фән өлкәсендәге кулланышларда күрәбез. Аллаһы Тәгалә хәмерне безгә карыныбызга кабул итәргә тыйды. Хәтта безнең тәнебез үзенә кирәк кадәр микъдарда спиртны үзенә үзе булдыра. Артыгы тәнебезгә зарар китерә, акылыбызны томалый һәм төрле җинаятьләргә этәрә. Бүгенге көндә Раббыбызның аятьләренә итагать итмичә хәмер кулланган кешеләрдән килгән зарарны бит санап бетергесез. Хәмер эчү сәбәпле күпме янгыннnар чыга, ул янгыннарда әти-әниләре белән бергә яшь сабый балаларның да һәлак булганнарын еш ишетәбез. Күпме юл фаҗигаләре була, сугышулар, кеше кыйнаулар, кеше үтерүләр, көчләүләр — күбесе бит исерек килеш эшләнә.

Дөньяга авыру зәгыйфь балалар туа, алар әти-әниләренең хәмер эчүләре аркасында гомерләре буе авыру бу- лып яшиләр. Җитештерү өлкәләрендә дә исерек килеш эшләнгән күмпе яраксыз товарлар, ватылган, яраксызга чыгарылган күпме җиһазлар бар. Ә иң куркынычы — хәмер бит безне Раббыбыздан ерагайта, йөрәгебезне каралта, акылыбыздан аера. Акыл — адәм баласына бирелгән иң олы нигъмәтләрнең берсе булып тора. Акыл белән без бүтән җан ияләреннән аерылып торабыз, начар белән яхшыны аерабыз. Ә хәмер безне шушы нигъмәттән мәхрүм итә. Аллаһы Тәгалә адәм баласына күркәм нәрсәләрне, игелекле гамәлләрне яратуны салган. Шуңа гөнаһлы гамәлләр адәм балаларына чиркангыч булып күренә. Һәм иблис тә моны белә, безне гөнаһка этәрүне җиңел түгел икәнен аңлый һәм безне юлдан яздыру өчен үзенең гасырлар буе кулланган коралларын куллана. Ул коралларның берсе булып хәмер тора. Әгәр иблис безгә хәмерне эчерә алса, соңыннан безнең белән курчак белән уйнаган шикелле уйнап, теләсә нинди гамәлләрен дә кылдыра ала.

Хәмер — ул шайтанның капканы. Ничек итеп аучы, үзенең корбанын totar өчен капканнар куеп, аның өстенә төрле җимнәр сипсә, без бүген хәмернең дә кибеттә яхшы урта бер урында, матур савытта булганын күрәбез. Хәтта балаларның эчемлекләре дә андый матур савытларда түгел. Бу капкан сыман: кем дә кем бу капканга үрелсә, белгәнебезчә, капкан ябыла һәм җим аучыныкына әйләнә. Хәмер эчкән кеше дә иблиснең кулында уйный башлый. Гаиләсен, әти-әнисен, күршеләрен һәм барча кешеләрне дә җәфалый башлый. Ахырда гаиләсен, эшен, дусларын югалтып, инде соңгы чиктә үзенә үзе кул салуга да җитүчеләрне күрәбез. Ә бит Раббыбыз кисәтте: «Мин сезгә гаһед кылмадыммы һәм белдермәдемме шайтанга гыйбадәт кылмагыз, вә аның сүзе белән йөрмәгез, әлбәттә, ул сезгә ачык дошмандыр» («Йәсин», 36:60).

Коръәни Кәримдә «Бәкара» сүрәсендә Аллаһ Раббыбыз әйтә: «Аллаһу Тәгалә хак мөэминнәрнең хуҗасы, аларны бидегәт, хорафәт караңгылыгыннан чыгарып, Коръән, сөннәт яктылыгына кертер. Аллаһуга яки Коръәнгә ышанмаган һәм Коръән белән гамәл кылмаган кешеләрне шайтан юлы булган бидегәт, хорафәт караңгылыгына кертер. Адашу караңгылыгында булган кешеләр — җәһәннәм уты әһелләре, алар анда мәңге калырлар» («Әл-Бәкара / Сыер», 2:257).

Хәмер кулланган кешеләрнең дә айлар буе айный алмыйча караңгылыкка һәм золымлыкка күчкәннәрен, көннән-көн йөзләре каралып, кешелек сыйфатларын югалтканнарын еш күреп яшибез. Ә ничек көрәшергә соң бүгенге көндә адәм баласы өчен зарарлы булган хәмерне куллanудан?

Тарих битләренә карасак, зур дәүләтләр дә хәмер белән көрәшеп карадылар. Безнең илдә дә хәмергә каршы көрәшеп, күпме виноград бакчаларын кистеләр, Америкада да коры закон чыгарып, күпме чыгымнар тотып, кешеләрне җәзаларга тартып көрәштеләр, әмма ахырда бу көрәштә җиңүче була алмадылар. Киресенчә, хәмер эчү киңрәк таралды һәм тамыр җәйде, хәтта хатын-кызлар, яшүсмерләр һәм балалар арасына да үтеп керде. Ә Пәйгамбәребез Мостафа (с.г.в.) гарәпләрне хәмердән аеру өчен бер дирһәм дә тотмады, бер виноград агачын да кисмәде, һәм һичкемне дә җәзага да тартмады. Әмма хәмерне судан да күбрәк эчкән гарәп халкын хәмердән аерды. Ничек Пәйгамбәребез (с.г.в.) бу эштә җиңүче булды? Берсүзсез, Аллаһның ярдәме вә Аның караңгылыктан нурга чыгаручы дине илә. Хәмергә һәм бүтән зарарлы нәрсәләргә каршы тору, алардан котылу һәм дәвалану чарасы — ул күңелләребезгә иман нуры кертү. Аллаһы Тәгаләне ярату, Аның әйткәннәрен үтәү һәм тыйганнарннан тыелу безне мәңгелек бәхеткә китерүче гамәл булып тора. Хәдис: «Аракы эчкән кеше — потка табынган кеше кебек».

Расүлебез Мөхәммәд (с.г.в.) әйтте: «Әгәр берәү Аллаһыга һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, хәмерне эчмәсен! Әгәр берәү Аллаһыга һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, хәмер эчелә торган өстәл артына утырмасын!». Хәмерне бары тик эчү генә гөнаһ түгел, ә аны ясау да, саклау да, сату да, ташучысы да бер үк гөнаһка китерә. «Раббыбыз хәмер эчүчене, эчерүчене, хәмерне сатып алучыны, сатучыны, ясаучыны, саклаучыны, ташучыны һәм үзенә ташытучыны ләгънәт кылды».

Бүгенге көндә күп сәүдәгәрләребезнең хәмер сатып бөтен яшьләребезне бозып, үзләре бай һәм бәхетле яшәргә омтылуларын күрәбез. Бәлки беренче мизгелдә ниндидер табышлар алсалар да, машиналар алып, зур йортлар корсалар да, көннәрдән бер көнне үзләре үк исерткән һәм хәмер эчүдә ярдәм иткән исерекләрдән бәла-каза һәм җәфа күрүдән беркем дә имин түгел. Аллаһ Раббыбыз безгә шайтан коткысы булган хәмер, наркотик һәм башка акылыбызны томалаучы хәрамнардан ерак булып, тәнебезгә, җаныбызга һәм иманыбызга файдалы булган, хәләл һәм пакь ризыклар белән ризыкланып яшәргә насыйп әйләсә иде. Бу дөнья безнең өчен бер сынау мәйданы. Ошбу дөньядагы сынауларыбызны, имтиханнарыбызны Аллаһ Раббыбыз җиңелллек белән үтәп, Ахирәттә мәңгелек җәннәтләренә кереп бетмәс нигъмәтләре белән нигъмәтләнергә насыйп әйләсә иде.

**Дамир хәзрәт Гыйниятуллин,**
**Кайбыч районы имам-мөхтәсибе.**

# Татарстан Диния нәзарәте 2017 елны “Галимҗан Баруди елы” дип игълан итте

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан 2017 ел “Галимҗан Баруди елы” дип игълан ителде. Ошбу тәкъдим белән 11 декабрьдә Диния нәзарәте бинасында үткән пленум җыелышында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин чыкты һәм ул бертавыштан хупланды.

“Быел татар дин әһеле, мөфти Галимҗан Барудиның тууына февраль аенда 160 ел тула. Галимҗан Баруди кебек танылган дин әһелләрен белергә, аларның китапларын укырга бу юбилей үзе бер сәбәп. Шуның өчен дә бу елны “Галимҗан Баруди елы” дип үткәрергә тәкъдим итәм һәм рухи мирасыбызны өйрәнергә чакырам”, - диде мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Галимҗан Баруди күренекле дин галиме, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, педагог. 1882 елда Г. Баруди мәдрәсә ача, ул анда җәдитчә укыта, әтисенең хөрмәтенә мәдрәсәгә “Мөхәммәдия” исеме бирә. 1906 елда Казанда аның мөхәррирлегендә «Әд-дин вәл-әдәб» (“Дин вә әхлак”) журналы чыга башлый. Баруди Россия мөселманнарының сәяси тормышында да актив катнаша. “Иттифак әл-мөслимин” мөселман фиркасе Үзәк комитетының әгъзасы итеп сайлана. Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте мөфтие вазыйфаларын да башкара.

Галимҗан Баруди 1921 елның 6 декабрендә Мәскәү каласында, ачларга ярдәм күрсәтү эшләре белән барган вакытында вафат була.

Г.Баруди гомере буе Шәрекъ халыкларының борынгы язма һәм басма китапларын җыю белән шөгыльләнеп, гаять бай китапханә туплаган була. Дүрт меңнән артык берәмлекне эченә алган бу китапханә 1920 елда дәүләт карамагына алынып, хәзерге вакытта Казан университеты фәнни китапханәсенең Көнчыгыш фонды нигезен тәшкил итә.

*Безгә язалар*

# Аллаһ илчесен зурладык

Районыбызның Кырынды авылына барган саен сокланып кайтам. Ике мәчет гөрләп эшләп тора. Быел Тәрдәле мәхәлләсе мәчетенә янкорма төзелеп мәдрәсә ачылды. Чаллының "Ак мәчет" мәдрәсәсендә белем алучы мөгаллимә Илсөяр ханым Зарипова ире имам-хатиб Зөфәр хәзрәт белән халыкны дингә кайтару буенча иҗтиһад кылалар. Күптән түгел монда Мәүлед аена багышланган мәҗлес гөрләп узды.

Ә миңа авылның Кырынды мәчетендә "Мәүлүдүн Нәби" мәҗлесендә катнашу насыйп булды. Гомумән, бу мәчеттә районда беренчеләрдән булып балалар һәм олыларны Ислам дине нигезләренә өйрәтү башланды. Шәкертләр "Ак мәчет" һәм "Кол Шәриф" мәчетләрнедә уздырылган республика күләмендәге бәйгеләрдә катнашып, мактаулы урыннар да яулады.

Бу юлы мәчеткә җитмешләп кунак җыелган иде. Алар күрше авыл мәхәлләлреннән, Әгерҗедән һәм Удмуртиядән. Мәүлид мәҗлесе татар теле укытучысы Рәмзия Гайнетдинованың чыгышыннан башланды. Ул пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тормыш юлын сөйләде, аның күркәм сыйфатларын - гүзәл әхлагын, олыны-кечене хөрмәт итүен, юмартлыгын, сабырлыгын күрсәткән мисаллар китерде. Мөгалимәләр Рәисә Кәримуллина, Мәгъфия Хаҗиевалар пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тормышы буенча викторина әзерләгәннәр иде. Бәйгедә олы яшьтәге ханымнарның да төгәл җавапларын ишетү бик күңелле булды.

Кадыбаш авылында тугыз балалы гаиләдә үсеп, 1968 елда Кырындыга килен булып төшкән Гөлнур Дәүләтшина авылның иң оста мөнәҗәтчесе булуын бу юлы дараслады. Күңелләргә үтеп керүче моңлы тавышлы Гөлнур ханым әйтүенчә, ул беренче мөнәҗәтләрне Кадыбаштагы курайчы әбидән өйрәнп калган.

Озак еллар район сәхнәсендә дан тоткан озын толымлы, көчле тавышлы җырчы Рәзилә Бикташеваны күпләр хәтерли. Хәзер ул үз мәкаме булган оста мөнәҗәтче. Элекке балалар бакчасы мөдире Салисә Гатауллина һәм китапханәче Сәүдә Мөхәммәтовалар дуэты да күңелгә ятышлы булды. Илүзә Миннәхмәтова һәм башка яшьләр авылда өлкән мөнәҗәтчеләргә лаеклы алмаш.

Мәҗлесне Рәисә абыстайның Коръән сүрәләре укып дәвам итүе нур өстенә нур булды. Ә инде пәйгамбәребезне (с.г.в.) олылап салават әйткәндә мәчет эчләре яктырып киткәндәй күренде. Хәдистә дә бит: "Берәр мәчеттә яисә өйдә Мөхәммәдне (с.г.в.) зурлап салаватлар әйтелсә, шул урынның халкына фәрештәләр үзләре салават әйтерләр һәм алардан Аллаһ разый булыр,"- диелгән.

# Яшьлек килә дә китә, картлык килә дә кала...

Якташ язучыбыз Габдулла Галиев язганча, адәм баласының кышлардан соң язы килми шул. Өлкәннәр яшәрә алмый, ә бар яшь кеше дә, Ходай гомер бирсә, картаячак. Баймы-ярлымы, матурмы-ямьсезме — барыбызга да проблемалары белән картлык килә. Карт кешенең холкы үзгәрә. Кайсы әби-бабай тормыш тәҗрибәсен, җан җылысын якыннарына өләшеп яши. Кайсы, Фатих Хөсни язганча, "Мыжык" картка әйләнә: һәр нәрсәдән гаеп табып, тирә-якгагыларга бәйләнеп яши. Яңәшәбездә ялгыз картайган өлкәннәр байтак. Сөйгән ярлары сугыштан кайтмаган "кыз-әбиләр", колхозда алны-ялны белми эшләп, шәхси тормышын көйләргә җитешми калган ялгызлар. Баласы булганнарның өмете бар әле. Элек-электән баласыз ятимнәрне якыннары сыендырган, картлар йортлары булмаган бит. Өчәр буын бергә яшәгән гаиләдә олыларны олы итү, аларга хөрмәт белән карау, сүз-киңәшенә колак салу шулай тиеш дип кабул ителгән. Булган, әлбәттә, тискәре үрнәкләр дә. Гыйбрәтле риваятьләр юктан барлыкка килмәгән бит. Аларның берсендә болай дип сурәтләнә: Усал киленнең сүзен тыңлап, улы картайган әтисен кабыкка салып далага — тау-таш арасына илтергә ниятләгән. Шунда бабасын яраткан оныгы: "Әти, кабыкны кире алып кайт, син картайгач, сине шуңа салып таулар арасына илтергә кирәк булыр бит,"- дип әтисенә сабак биргән.

Мин мәктәптә укыганда еш кына авылдан Әгерҗегә әнкәйнең Бәдертдин абыйсына кунакка килә идем. Шул елларда алар Оркыя җиңгинең кайсы яктан туган икәнен дә белмәгән Майҗиян түтине карадылар. Инде медучилищеда укыганда юл уңаеннан кереп йөргәндә икенче әби пәйда булды. Икесен дә тәрбияләп соңгы юлга озаттылар. Улсәләр - өйләре кала дип тә, акча өчен дә карамадылар бит. Әбиләрнең берсе бөтенләй пенсия дә алмый иде. Аллаһ ризалыгы өчен, савап өчен мәрхәмәт кылдылар.

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә: "Бер кеше үз ятимен яки башка кеше ятимен тәрбияләсә, аңа җәннәт вәҗип булыр,"- диелгән.

Хөкүмәттә ялгыз әби-бабайларны гаиләләргә асрамага бирү пилот-проекты эшләнеп ята. Картлар йортыннан йолкып алып тәрбияләргә теләүче гаиләгә тапшыру да чираттагы "прожект" булып чыкмас микән? Карт агачны төбе-тамыры белән йолкып чыгарып, яңа туфракта үсеп китә алырмы? "Мунча ташы" эстрада театрының бер күренешендә "Юньле карчык 70 тә үлә ул" дигәндәй, хөкүмәтебез өлкәннәрнең тизрәк үлеп бетүен тели бугай. Сугыш чоры балаларына акча түләүне сузу да шуның билгесе түгелме? Үзем аралашып сорашу үткәргән кешенең күбесе: "Акчасына кызыгып кына алачаклар,"- дигән фикердә. Сәламәтлеге әйбәт булган ялгызакны алып та, иртәгә аңа инсульт булса, кире илтеп бирерләрме? Олы кешенең еш кына башы да "авыша". Андыйны балалар янында гаиләдә тотсаң, проблемалар чыгасын көт тә тор. Минә шулай, җиде кат үлчәргә кирәк әле моны.

Аллаһ теләсә, берничә берничә миһербанлы гаилә табылыр, әлбәттә. Аларга пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисен китереп үтәм: "Мәрхәмәтле кешеләргә Аллаһы рәхмәтле. Җир йөзендә булганнарга сез мәрхәмәт итегез, күктә булганнар сезгә мәрхәмәт итәрләр."

Аллаһка тапшырдык инде.

Редакция игътибарына: Бәлки газета битләрендә аралашу башлап җибәрергәдер, кем ничек карый икән бу мәсьәләгә?

**Рәмзия Шәймөхәммәтова**
**Әгерҗе шәһәре.**

# 2017 елның I яртыеллыгына газетабызга язылу йомгаклары

**I графа – район, өлкә, республика; II – язылучылар саны; 2016 елның I яртыеллыгы белән чагыштырганда арткан (+) яки кимегән (-)**

**Татарстан буенча**

| | | |
|---|---|---|
| Әгерҗе | 9 | - 3 |
| Азнакай | 16 | - 1 |
| Аксубай | 15 | -7 |
| Актаныш | 9 | -13 |
| Алексеевск | 1 | -3 |
| Әлки | 10 | |
| Әлмәт | 9 | - 6 |
| Апас | 1 | -20 |
| Арча | 19 | |
| Әтнә | 2 | |
| Баулы | 5 | -3 |
| Балтач | 9 | -12 |
| Бөгелмә | 1 | |
| Буа | 4 | -7 |
| Болгар | 4 | -2 |
| Биектау | 5 | - 2 |
| Балык Бистәсе | 7 | - 5 |
| Чүпрәле | 7 | - 3 |
| Алабуга | 7 | - 3 |
| Зәй | 25 | +2 |
| Яшел Үзән | 10 | +2 |
| Кайбыч | 4 | |
| Кама Тамагы | 1 | -4 |
| Кукмара | 16 | - 1 |
| Лаеш | 2 | - 3 |
| Лениногорск | 10 | - |
| Мамадыш | 4 | - 9 |
| Минзәлә | 24 | - 6 |
| Мөслим | 17 | + 2 |
| Түбән Кама | 1 | - 2 |
| Яңа Чишмә | 3 | - 5 |
| Норлат | 7 | - 7 |
| Питрәч | 5 | - 1 |
| Саба | 4 | - 7 |
| Сарман | 33 | +10 |
| Чаллы | 346 | |
| Чирмешән | 3 | |
| Чистай | 7 | -7 |
| Менделеевск | 7 | +2 |
| Урыссу | 2 | - 3 |
| Теләче | 4 | + 3 |
| Казан | 12 | - 2 |
| **Җәмгысе** | **725** | **-125** |

**Татарстаннан читтә**

| | | |
|---|---|---|
| Башкортостан | 156 | +23 |
| Нижний Новгород | 27 | +21 |
| Киров | 18 | + 6 |
| Красноярск | 2 | + 1 |
| Томск | 1 | |
| Курган | 2 | |
| Пенза | 3 | - 2 |
| Пермь | 11 | + 2 |
| Самара | 4 | |
| Свердловск | 4 | |
| Саратов | 1 | - 2 |
| Омск | 7 | + 3 |
| Оренбург | 17 | + 1 |
| Чиләбе | 8 | + 1 |
| Чувашстан | 7 | + 1 |
| Удмуртия | 1 | |
| Ульяновск | 8 | + 4 |
| Мордовия | 1 | |
| Әстерхан | 1 | |
| Мәскәү | 2 | |
| **Җәмгысе** | **295** | **+89** |

**Башкортостан буенча**

| | | |
|---|---|---|
| Уфа | 5 | + 1 |
| Толбазы | 1 | - 1 |
| Раевка | 4 | + 2 |
| Бирск | 1 | |
| Бүздәк | 2 | + 1 |
| Борай | 27 | +10 |
| Мәсәгут | 16 | + 3 |
| Дәүләкән | 1 | |
| Дүртөйле | 5 | - 2 |
| Иглин | 3 | + 2 |
| Караидел | 2 | |
| Кырмыскалы | 28 | - 3 |
| Туймазы | 12 | +2 |
| Чакмагыш | 15 | - 5 |
| Янаул | 7 | + 3 |
| Стәрлетамак | 14 | +10 |
| Малояз | 1 | |
| Мәләүз | 7 | - 1 |
| Күмертау | 3 | + 2 |
| Сибай | 1 | - 1 |
| Баймак | 1 | |

# Намаз вакытлары

| Милади февраль | Көн исеме | Җөм. аү. Җөм. ахир. | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ясту Уфа | Ясту Чаллы | Ясту Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Чш | 4 | 07.01 | 05.16 | 05.29 | 07.36 | 05.54 | 06.08 | 09.06 | 07.24 | 07.38 | 13.29 | 11.43 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.01 | 14.12 | 14.25 | 17.52 | 16.03 | 16.16 | 19.37 | 17.50 | 18.03 |
| 2 | Пж | 5 | 06.59 | 05.14 | 05.28 | 07.34 | 05.53 | 06.06 | 09.04 | 07.23 | 07.36 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.03 | 14.14 | 14.26 | 17.54 | 16.05 | 16.18 | 19.38 | 17.52 | 18.05 |
| 3 | Җм | 6 | 06.58 | 05.13 | 05.26 | 07.32 | 05.51 | 06.04 | 09.02 | 07.21 | 07.34 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.05 | 14.16 | 14.28 | 17.56 | 16.07 | 16.20 | 19.40 | 17.54 | 18.07 |
| 4 | Шм | 7 | 06.56 | 05.11 | 05.24 | 07.31 | 05.49 | 06.02 | 09.01 | 07.19 | 07.32 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.07 | 14.18 | 14.30 | 17.58 | 16.10 | 16.23 | 19.42 | 17.56 | 18.09 |
| 5 | Як | 8 | 06.55 | 05.10 | 05.23 | 07.29 | 05.47 | 06.00 | 08.59 | 07.17 | 07.30 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.09 | 14.20 | 14.32 | 18.00 | 16.12 | 16.25 | 19.44 | 17.58 | 18.11 |
| 6 | Дш | 9 | 06.53 | 05.08 | 05.21 | 07.27 | 05.45 | 05.58 | 08.57 | 07.15 | 07.28 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.11 | 14.22 | 14.34 | 18.03 | 16.14 | 16.27 | 19.45 | 17.59 | 18.13 |
| 7 | Сш | 10 | 06.51 | 05.06 | 05.19 | 07.25 | 05.43 | 05.56 | 08.55 | 07.13 | 07.26 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.13 | 14.24 | 14.36 | 18.05 | 16.16 | 16.29 | 19.47 | 18.01 | 18.14 |
| 8 | Чш | 11 | 06.50 | 05.05 | 05.18 | 07.23 | 05.41 | 05.54 | 08.53 | 07.11 | 07.24 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.15 | 14.26 | 14.38 | 18.07 | 16.18 | 16.31 | 19.49 | 18.03 | 18.16 |
| 9 | Пж | 12 | 06.48 | 05.03 | 05.16 | 07.21 | 05.38 | 05.52 | 08.51 | 07.08 | 07.22 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.17 | 14.28 | 14.40 | 18.09 | 16.20 | 16.33 | 19.51 | 18.05 | 18.18 |
| 10 | Җм | 13 | 06.46 | 05.01 | 05.14 | 07.19 | 05.36 | 05.50 | 08.49 | 07.06 | 07.20 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.19 | 14.30 | 14.42 | 18.11 | 16.23 | 16.36 | 19.53 | 18.07 | 18.20 |
| 11 | Шм | 14 | 06.44 | 04.59 | 05.12 | 07.17 | 05.34 | 05.47 | 08.47 | 07.04 | 07.17 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.21 | 14.32 | 14.44 | 18.13 | 16.25 | 16.38 | 19.55 | 18.09 | 18.22 |
| 12 | Як | 15 | 06.43 | 04.57 | 05.10 | 07.15 | 05.32 | 05.45 | 08.45 | 07.02 | 07.15 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.23 | 14.33 | 14.46 | 18.15 | 16.27 | 16.40 | 19.56 | 18.11 | 18.24 |
| 13 | Дш | 16 | 06.41 | 04.55 | 05.08 | 07.12 | 05.30 | 05.43 | 08.42 | 07.00 | 07.13 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.24 | 14.35 | 14.48 | 18.17 | 16.29 | 16.42 | 19.58 | 18.13 | 18.26 |
| 14 | Сш | 17 | 06.39 | 04.53 | 05.06 | 07.10 | 05.28 | 05.41 | 08.40 | 06.58 | 07.11 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.26 | 14.37 | 14.50 | 18.19 | 16.31 | 16.44 | 20.00 | 18.15 | 18.28 |
| 15 | Чш | 18 | 06.37 | 04.51 | 05.04 | 07.08 | 05.25 | 05.39 | 08.38 | 06.55 | 07.09 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.28 | 14.39 | 14.52 | 18.21 | 16.34 | 16.47 | 20.02 | 18.17 | 18.30 |
| 16 | Пж | 19 | 06.35 | 04.49 | 05.02 | 07.06 | 05.23 | 05.36 | 08.36 | 06.53 | 07.06 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.30 | 14.41 | 14.54 | 18.23 | 16.36 | 16.49 | 20.04 | 18.19 | 18.32 |
| 17 | Җм | 20 | 06.33 | 04.47 | 05.00 | 07.04 | 05.21 | 05.34 | 08.34 | 06.51 | 07.04 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.32 | 14.43 | 14.56 | 18.26 | 16.38 | 16.51 | 20.06 | 18.21 | 18.34 |
| 18 | Шм | 21 | 06.31 | 04.45 | 04.58 | 07.02 | 05.19 | 05.32 | 08.32 | 06.49 | 07.02 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.34 | 14.45 | 14.58 | 18.28 | 16.40 | 16.53 | 20.08 | 18.23 | 18.36 |
| 19 | Як | 22 | 06.29 | 04.43 | 04.56 | 06.59 | 05.16 | 05.29 | 08.29 | 06.46 | 06.59 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.36 | 14.47 | 15.00 | 18.30 | 16.42 | 16.55 | 20.10 | 18.24 | 18.38 |
| 20 | Дш | 23 | 06.27 | 04.41 | 04.54 | 06.57 | 05.14 | 05.27 | 08.27 | 06.44 | 06.57 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.38 | 14.49 | 15.02 | 18.32 | 16.44 | 16.57 | 20.11 | 18.26 | 18.40 |
| 21 | Сш | 24 | 06.25 | 04.38 | 04.51 | 06.55 | 05.12 | 05.25 | 08.25 | 06.42 | 06.55 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.40 | 14.51 | 15.04 | 18.34 | 16.46 | 17.00 | 20.13 | 18.28 | 18.42 |
| 22 | Чш | 25 | 06.22 | 04.36 | 04.49 | 06.53 | 05.09 | 05.22 | 08.23 | 06.39 | 06.52 | 13.29 | 11.43 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.41 | 14.53 | 15.06 | 18.36 | 16.49 | 17.02 | 20.15 | 18.30 | 18.44 |
| 23 | Пж | 26 | 06.20 | 04.34 | 04.47 | 06.50 | 05.07 | 05.20 | 08.20 | 06.37 | 06.50 | 13.29 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.43 | 14.55 | 15.08 | 18.38 | 16.51 | 17.04 | 20.17 | 18.32 | 18.46 |
| 24 | Җм | 27 | 06.18 | 04.32 | 04.45 | 06.48 | 05.04 | 05.18 | 08.18 | 06.34 | 06.48 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.45 | 14.57 | 15.10 | 18.40 | 16.53 | 17.06 | 20.19 | 18.35 | 18.48 |
| 25 | Шм | 28 | 06.16 | 04.29 | 04.42 | 06.46 | 05.02 | 05.15 | 08.16 | 06.32 | 06.45 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.47 | 14.59 | 15.12 | 18.42 | 16.55 | 17.08 | 20.21 | 18.37 | 18.50 |
| 26 | Як | 29 | 06.13 | 04.27 | 04.40 | 06.43 | 05.00 | 05.13 | 08.13 | 06.30 | 06.43 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.49 | 15.01 | 15.14 | 18.44 | 16.57 | 17.10 | 20.23 | 18.39 | 18.52 |
| 27 | Дш | 30 | 06.11 | 04.24 | 04.37 | 06.41 | 04.57 | 05.10 | 08.11 | 06.27 | 06.40 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.51 | 15.03 | 15.16 | 18.46 | 16.59 | 17.12 | 20.25 | 18.41 | 18.54 |
| 28 | Сш | 1 | 06.09 | 04.22 | 04.35 | 06.38 | 04.55 | 05.08 | 08.08 | 06.25 | 06.38 | 13.28 | 11.42 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.52 | 15.04 | 15.17 | 18.48 | 17.01 | 17.14 | 20.27 | 18.43 | 18.56 |

## Хәләл ризыкка дегустация



**Рәсемдә:** "Хәләл-Үзәк"тәге дегустациядән күренеш.

Рәсәйдә иң күп хәләл тавык ите җитештерүче "Чаллы-Бройлер" җәмгыяте үз продукциясен башка төбәкләрдә таныту буенча эш алып бара. Яңа ел алдыннан аны авыз итү (дегустация) чарасы Башкортостанда, Норлат шәһәрендә, Чаллының "Хәләл Үзәге"ндә узды. Үзәккә килүчеләр тавык итеннән җитештерелгән рулет, "Купец ипие", "Рәхмәт" тутырмасы белән таныштылар. Хәләл ризыкларны авыз итүчеләр аларга югары бәя бирде.

Дегустация үткәрүче Эмилия Захарова белдерүенчә, "Чаллы-Бройлер"ның хәләл продукциясе моңа кадәрге авыз итүләрдә дә югары бәяләнгән.

Дегустация вакытында сатып алучыларга "Чаллы-Бройлер"да хәләл продукция җитештерү процессы, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы Хәләл стандарты комитеты эшчәнлеге турында клиплар, тапшырулар да күрсәтелә.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 2000.**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 13 гыйнвар 16 сәг., фактта 13 гыйнвар 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**